РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2022 елның 18 ноябре Кукмара ш. № 150

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының 2023 елга 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджеты проекты турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тәкъдим иткән Кукмара муниципаль районының 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджет проектын «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Кукмара муниципаль районы Уставы, Кукмара муниципаль районы Советы нигезендә карап тикшергәннән соң **карар:**

1. Кукмара муниципаль район Советының «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына бюджеты турында» карар проектын хупларга һәм халык алдында тыңлауларга чыгарырга (1 нче кушымта).

2. Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга:

1) «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында» Кукмара муниципаль район Советының карар проекты (1 нче кушымта);

2) «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында» Кукмара муниципаль район Советының карар проектына гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе (2 нче кушымта).

3. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында» Кукмара муниципаль район Советының карар проекты буенча кергән тәкъдимнәрне исәпкә алу, гомумиләштерү һәм карап тикшерү буенча түбәндәге составта эшче төркем оештырырга:

Гаянова Р.Н – Кукмара муниципаль районы Башлыгы урынбасары;

Гыйззәтуллина Г.А. – Кукмара муниципаль районы Советының Законлылык һәм хокук тәртибе буенча даими комиссия рәисе;

Хәбибрахманов Г.Х. – Икътисади сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссия рәисе;

Сәмигуллин И.К. – Кукмара муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе;

Ходова И.В. – Кукмара муниципаль районы Советының Хокук һәм кадрлар белән тәэмин итү бүлеге башлыгы.

4. «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында» Кукмара муниципаль район Советының карар проекты буенча Кукмара район Советының 2018 елның 27 июлендәге 168 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (иҗтимагый фикер алышуларны) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә гавами тыңлаулар үткәрергә.

5. Билгеләргә:

5.1. Гавами тыңлаулар үткәрү көне – 2022 елның 6 декабре.

5.2. Гавами тыңлаулар үткәрү вакыты – 9:00 сәгать.

5.3. Уздыру урыны – ТР, Кукмара шәһәре, Ленин урамы, 38 йорт адресы буенча район Мәдәният йорты.

6. Эшче төркемгә «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Кукмара муниципаль районы бюджеты турында» Кукмара муниципаль район Советының карар проекты буенча Кукмара муниципаль районы Советы депутатларының һәм гражданнарның тәкъдимнәрен өйрәнергә һәм гомумиләштерергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кукмара муниципаль районы-Башлыгы урынбасары Р.Н. Гаяновага йөкләргә.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев

Проект

КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

КАРАР

2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының бюджеты турында

Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителгән 2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты проектын карап, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

**1 статья**

1. 2023 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең фаразлана торган гомуми күләме 1 840 259 940,00 сум;

2) Кукмара муниципаль районы бюджетының гомуми чыгымнары күләме 1 840 259 940,00 сум;

3) Кукмара муниципаль районы бюджеты дефициты (профициты) 0 сум күләмендә.

2. 2024 елга һәм 2025 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кукмара муниципаль районы бюджеты керемнәренең 2024 елга фаразлана торган гомуми күләмен 1 837 122 250,00 сум һәм 2025 елга 1 851 280 710,00 сум күләмендә;

2) Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2024 елга 1 837 122 250,00 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 17 825 700 сум һәм 2025 елга 1 851 280 710,00 сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 38 133 700 сум;

3) Кукмара муниципаль районының 2024 елга бюджет дефициты (профициты) 0 сум, 2025 елга 0 сум күләмендә.

3. Кукмара муниципаль районы бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын түбәндәгечә билгеләргә:

2023 елга әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә;

2024 елга һәм 2025 елга әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә.

2 **статья**

2. 2024 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

Кукмара муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

3. 2025 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

Кукмара муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

3. 2026 елның 1 гыйнварына торышы буенча билгеләргә:

Кукмара муниципаль районының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль бурычның иң югары чиге ноль сум күләмендә, шул исәптән муниципаль гарантияләр буенча ноль сум күләмендә.

**3 статья**

Кукмара муниципаль районы бюджетында 2023 елга Кукмара муниципаль районы бюджетының фаразланыла торган керем күләмен әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**4 статья**

2023 елга Кукмара муниципаль районының Юл фондының бюджет ассигнованиеләре күләмен 31 600 мең сум, 2024 елга 31 200 мең сум күләмендә, 2025 елга 32 200 мең сум күләмендә расларга һәм ааларны 2023, 2024 һәм 2025 елларга Кукмара муниципаль районының гомуми файдаланудагы юл эшләре программасы чараларын тормышка ашыруга юнәлдерергә.

**5 статья**

1. Бюджет ассигнованиеләрен бюджет чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнары төрләре буенча бүлүне расларга:

2023 елга әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә;

2024 һәм 2025 елларга әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә;

2. Кукмара муниципаль районы бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга:

2023 елга әлеге карарга 7 нче кушымта нигезендә;

2024 һәм 2025 елларга әлеге карарга 8 нче кушымта нигезендә;

3. Гавами норматив йөкләмәләрне үтәү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләмен 9 нчы кушымта нигезендә 2023 елга 1 161 000,00 сум, 10 нчы кушымта нигезендә 2024 елга 1 161 000,00 00 сум һәм 2025 елга 1 161 000,00 сум күләмендә расларга.

**6 статья**

1. Кукмара муниципаль районы бюджетына Кукмара шәһәре бюджетыннан муниципаль торак фондын капиталь ремонтлауга төзелгән килешү нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга

2023 елга – 4 388 000 сум күләмендә, 2024 елга 4 388 000 сум, 2025 елга 4 388 000 сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар күләмен исәпкә алырга.

2. Финанс контроленә төзелгән килешү нигезендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга Кукмара муниципаль районы бюджетына җирлекләр бюджетларыннан башка бюджетара трансфертлар күләмен 2023 елга 684 000 сум күләмендә, 2024 елга 684 000 сум, 2025 елга 684 000 сум күләмендә башка бюджетара трансфертлар күләмен 11 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

**7 статья**

Җирлекләрнең бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә җирлекләр бюджетларына дотацияләр күләмен расларга:

әлеге карарга 12 нче кушымта нигезендә бүлеп, 2023 елга 49 443 900 сум күләмендә,

әлеге карарга 13 нче кушымта нигезендә бүлеп, 2024 елга 47 158 300 сум күләмендә,

әлеге карарга 14 нче кушымта нигезендә бүлеп, 2025 елга 48 679 640 сум күләмендә.

**8 статья**

Кукмара муниципаль районы бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм җирлек бюджетларыннан алына торган бюджетара трансфертлар күләмен исәпкә алырга:

әлеге карарга 15 нче кушымта нигезендә бүлеп, 2023 елга 1 230 422 640,00 сум күләмендә,

әлеге карарга 16 нчы кушымта нигезендә бүлеп, 2024 елга 1 203 161 850,00 сум күләмендә,

әлеге карарга 16 нчы кушымта нигезендә бүлеп, 2025 елга 1 187 550 310,00 сум күләмендә.

**9 статья**

1. Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләренең санын, шулай ук аларны тоту чыгымнарын арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

2. Җирле үзидарә органнарына 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына муниципаль хезмәткәрләр һәм бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм оешмалары хезмәткәрләренең санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә.

**10 статья**

Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләүдән, әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге административ хокук бозулар өчен административ штрафлардан, әйләнә-тирәлеккә, шул исәптән су объектларына мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында китерелгән зыянны каплау турында дәгъвалар

буенча түләүләрдән, шулай ук әйләнә-тирә мохиткә, шул исәптән су объектларына мәҗбүри таләпләрне бозу аркасында китерелгән зыянны ирекле каплаганда түләнә торган түләүләрдән җирле бюджетка кертелгән салым булмаган керемнәр Татарстан Республикасының әйләнә-тирәлекне саклау өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органы тарафыннан раслана торган табигатьне саклау чаралары планы нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле башкарма хакимиятнең федераль органы белән килештереп, әйләнә-тирәлеккә җыелган зыян объектларын ачыклау һәм бәяләүгә һәм әйләнә-тирә мохиткә җыелган зыянны бетерү эшләрен оештыруга, әйләнә-тирәлеккә хуҗалык эшчәнлегенең һәм башка эшчәнлекнең тискәре йогынтысын булдырмау һәм (яки) киметү, табигый тирәлекне саклау һәм торгызу, табигый ресурслардан рациональ файдалану һәм яңадан торгызу, экологик куркынычсызлыкны тәэмин итү буенча башка чараларга юнәлтелә

**11 статья**

Кукмара муниципаль районыны бюджетыннан Кукмара муниципаль районы исеменнән товарлар белән тәэмин итүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар төзелгән өчен файдаланылмаган, әлеге муниципаль контрактларның шартлары нигезендә 2022 елда түләнергә тиешле бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә акча калдыклары, Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, 2023 елда әлеге максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

**12 статья**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Кукмара районы буенча Казначылык Департаментының территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Кукмара муниципаль районы бюджетын үтәү буенча аерым функцияләр башкара.

**13 статья**

Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

**14 статья**

Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С.Д. Димитриев